# IV ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ II СЕССИЯСЕ

**К А Р А Р № 15**

Мөслим «13» ноябрь 2020 ел

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы милкендәге җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмнәрен билгеләү турында» 2016 елның 11 апрелендәге 34 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы карарына үзгәреш кертү хакында**

Эшкуарлыкка дәүләт ярдәме күрсәтү һәм милекнең төрле рәвешләренә нигезләнгән җитештерү, төзелеш, сәүдә-арадашчылык һәм башка эшчәнлекне үстерү өчен тигез шартлар булдыру максатларында, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы милкендәге җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмнәрен билгеләү турында» 2016 елның 11 апрелендәге 34 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« Әлеге нигезләмә, 1.10 пунктыннан тыш, сату-алуларда җир кишәрлекләрен арендага бирү очракларына кагылмый.»;

1 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 1.4-1.9 пунктлар өстәргә:

«1.4. Россия Федерациясе Җир кодексының 49 статьясындагы 2 пунктында каралган объектларны урнаштыру өчен, шулай ук җир асты байлыкларыннан файдалану белән бәйле эшләрне башкару өчен бирелгән җир кишәрлекләренә аренда түләве башкарма хакимиятнең федераль органнары тарафыннан расланган аренда түләве ставкалары белән исәпләнә.

1.5. Россия Федерациясе Җир кодексының 39.7 статьясындагы 5 пункты нигезендә аренда шартнамәсе төзелгән очракта, җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләме мондый җир кишәрлегенә карата исәпләнгән җир салымы күләмендә билгеләнә.

1.6. Әгәр җир кишәрлегендә файдалануның берничә төре гамәлгә ашырылса, аренда түләвен исәпләү максатларында җир кишәрлегеннән файдалану төрен исәпкә ала торган иң зур төзәтмә коэффициенты кулланыла.

1.7. Җир кишәрлекләрендә офис инфраструктурасын кулланып (үзәкләштерелгән кабул итү бүлмәләрен, очрашулар үткәрү бүлмәләрен, офис җиһазларын, парковкаларны да кертеп) бинаның, корылманың, урынның гомуми мәйданыннан 20% артмаган мәйданда җитештерү эшчәнлеге башкарылган очракта, аренда түләве җитештерү эшчәнлеге өчен кулланыла торган ставка буенча алына.

1.8. Җир кишәрлегенең кадастр бәясе үзгәргәндә аренда түләве, җир кишәрлегенең кадастр бәясе үзгәргән елдан соң килүче елның 1 гыйнварына кадәр яңадан исәпләнергә тиеш.

Җир кишәрлегенең кадастр бәясе үзгәрүгә бәйле рәвештә аренда түләвен

үзгәртү мөмкинлеге җир кишәрлеген арендалау шартнамәсендә каралган.

1.9. Күчемсез милек дәүләт кадастрында җир кишәрлегенең кадастр бәясе билгеләнмәгән яисә 0 яки 1 сумга тиң күләмдә күрсәтелмәгән очракта, аренда түләвен исәпләү җир кишәрлегенең базар бәясе нигезендә башкарыла.»;

2.3.пункты үз көчен югалткан дип танырга;

Нигезләмәгә кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (Кушымта).

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы Рәисенә йөкләргә.

Мөслим муниципаль районы Башлыгы,
Мөслим муниципаль районы Советы рәисе Р.Х. Муллин

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Советының 2020 елның
«13» ноябрендәге 15 номерлы
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мөслим
муниципаль районы милкендәге
җир кишәрлекләре өчен
аренда түләве күләмнәрен билгеләү
тәртибе турындагы Нигезләмәгә
кушымта

**Җир кишәрлегеннән файдалану төрен исәпкә алган төзәтмә коэффициентлары исемлеге**

| **Җир кишәрлегеннән файдалану төре** | **Коэффициент** |
|---|---|
| Медицина, социаль, психологик, юридик ярдәм күрсәтү өчен билгеләнгән хәйрия фондлары бинаалары, төзелмәләре һәм корылмалары өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 0,01 |
| «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында төзелә торган торак һәм объектларны урнаштыру өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 0,1 |
| Граждан авиациясе объектлары өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 0,1 |
| Махсуслаштырылган тукталу урыннары (тоткарланган транспорт чаралары тукталу урыннары (төзелеш чорын да кертеп) | 0,1 |
| Чистарту корылмалары объектлары өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 0,1 |
| Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау учреждениеләрендә дәваланучы гражданнарга, аларны озатучы затларга вакытлыча бушлай тору өчен аталган объектлар өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 0,1 |

| | |
|---|---|
| «Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законга таянып төзелгән шартнамәләр, килешүләр нигезендә төзү, төзелеш, эксплуатация, реконструкция модернизацияләү гамәлгә ашырыла торган гидротехник корылмалар өчен (су ресурсларыннан файдалану һәм аларны саклау өчен билгеләнгән, суларның, шул исәптән сыек калдыклар белән, плотиналар, су аттыру, су үткәрү һәм су чыгару корылмаларын да кертеп, суларның зарарлы йогынтысын булдырмау өчен билгеләнгән су мохите йогынтысына дучар булган корылмалар; насос станцияләре; суднолар йөри торган шлюзалар; суднолар күтәргечләр; су басулардан, сусаклагычларның ярлары җимерелүдән, елгаларның ярлары һәм төпләре җимерелүдән саклау өчен билгеләнгән корылмалар; су саклау корылмалары; дамбалар, яр ныгыту корылмалары, яр буйлары, шул исәптән аларда урнашкан төзекләндерү һәм коммерция инфраструктурасы объектлары; пирслар; техник су белән тәэмин итү системалары корылмалары) (төзелеш чорын да кертеп) | 0,1 |
| 2017 елның 1 гыйнварыннан соң Россия Федерациясе Җир кодексының 39^ статьясындагы 2 пунктының 25 пунктчасы нигезендә үз һәм (яки) заем акчалары исәбеннән төзелгән аренда шартнамәләре нигезендә гамәлгә ашырыла торган гидротехник корылмалар (су ресурсларыннан файдалану һәм аларны саклау өчен билгеләнгән, суларның, шул исәптән сыек калдыклар белән, плотиналар, су аттыру, су үткәрү һәм су чыгару корылмаларын да кертеп, суларның зарарлы йогынтысын булдырмау өчен билгеләнгән су мохите йогынтысына дучар булган корылмалар; насос станцияләре; суднолар йөри торган шлюзалар; суднолар күтәргечләр; су басулардан, сусаклагычларның ярлары җимерелүдән, елгаларның ярлары һәм төпләре җимерелүдән саклау өчен билгеләнгән корылмалар; су саклау корылмалары; дамбалар, яр ныгыту корылмалары, яр буйлары, шул исәптән аларда урнашкан төзекләндерү һәм коммерция инфраструктурасы объектлары; пирслар; техник су белән тәэмин итү системалары корылмалары) өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 0,1 |
| Спорт объектлары һәм корылмалары өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 0,17 |
| Россия Федерациясе Җир кодексының 39^ статьясы 2 пунктының 3 пунктчасы нигезендә бирелгән җир кишәрлекләрендә урнашкан сәламәтлек саклау объектлары өчен | 0,5 (җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе төзелгән вакыттан алып 5 елга) |
| Авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен | 1,0 |

| | |
|---|---|
| Торак урнаштыру, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача төзелеше өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 1,0 |
| Җитештерү өлкәсе объектлары өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 1,0 |
| Электр станцияләрен, аларга хезмәт күрсәтүче корылмаларны һәм объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән объектлар өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 1,0 |
| Портлар, су, автоюл вокзаллары, аэровокзаллар урнаштыру өчен билгеләнгән объектлар өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 1,0 |
| Файдалы казылмалар чыгару өчен, ясалма төзелгән эчке су юлларын, причаллар, пристаньнар, автомобиль юлларының бүленгән полосасы, су юллары, торбаүткәргечләр, элемтәнең кабель,радиореле һәм һава линияләре һәм радиофикация линияләре, электр тапшыруның һава линияләре, конструктив элементлар һәм корылмалар, корылмаларның конструкциягә караган элементлары, җир өсте һәм җир асты биналары, төзелешләр, корылмалар, транспорт, энергетика һәм элемтә җайланмалары өчен кирәкле булган объектларны карап тоту, төзү, реконструкцияләү, ремонтлау, үстерү өчен кирәкле булган объектларны урнаштыру өчен аталган объектларга; спутник элемтәсенең җир өсте корылмаларын һәм инфраструктурасын, космик эшчәнлек объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән объектларга; җир өсте корылмаларын һәм спутник элемтәсе инфраструктурасын урнаштыру (төзелеш чорын да кертеп) | 1,0 |
| Склад объектлары өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 1,0 |
| Гараж өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 1,0 |
| Ябык күп катлы һәм җир асты автомототранспорт тукталу урыннары өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 1,0 |
| Төзелеш чорында ябык күп катлы автомототранспорт тукталу урыннары өчен (шул исәптән төзелеш чорын да) | 1,0 |
| Рекреация һәм дәвалау-сәламәтләндерү объектлары өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 1,0 |
| Әйләнештәге су объектлары өчен | 1,0 |
| Скверлар, парклар урнашкан объектлар өчен | 1,0 |
| Башка объектлар өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 2,0 |
| Административ биналар, урын һәм офислар өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 2,0 |
| Автомототранспортның ачык стоянкалары өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 3,0 |
| Күпләп сату объектлары өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 4,0 |
| Җәмәгать туклануы объектлары өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 4,0 |
| Автосервис объектлары һәм автомобильләргә ягулык салу станцияләре өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 4,5 |
| Кунакханәләр өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 5,0 |
| Ваклап сату объектлары (кибетләр, сәүдә мәйданы булган | 10,0 |

| | |
|---|---|
| павильоннар, вак сату киосклары), базарлар, даруханәләр өчен (төзелеш чорын да кертеп) | |
| Банк, иминият, биржа эшчәнлеге объектлары, шул исәптән түләү терминаллары өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 10,0 |
| Реклама объектлары (нигезләрдә урнашкан реклама щитлары һәм стендлар) өчен (төзелеш чорын да кертеп) | 75,0 |